**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Олы Нөркәй авыл җирлегенең аерым территориясендә хайваннар котыру авырулы булганга, аның имин булмавы сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерү турында**

Котыру чиренә бирешүчән соңгы авыру хайванның үләксәсе юкка чыгарылган көннән 60 календарь көн узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Олы Нөркәй авыл җирлеге Олы Нөркәй авылындагы С.Рәфыйков урамы 97 нче йортта урнашкан шәхси йорт хуҗалыгы территориясендә һәм «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Олы Нөркәй авыл җирлегендә урнашкан, эпизоотия чыганагы чикләреннән 2 км радиустагы территориядә хайваннар котыру авырулы булганга, аларның имин булмавы сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерергә.

2. Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Олы Нөркәй авыл җирлегенең аерым территориясендә хайваннар котыру авырулы булганга, аның имин булмавы сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2025 елның 8 августындагы 622 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы
Рәисе**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2025 ел, 10 октябрь
№ 847